## А.С.ЯКИМОВ:

# «ЮГАРЫ ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК, ТАР БЕЛГЕЧЛЕК – КАДРЛАРГА ТАЛӘП ШУНДЫЙ»

***Ике ел элек Россия инновацион ягулык - энергетика компаниясе (РИТЭК) идарәсе Мәскәүдә) Норлатта үзенең чираттагы предприятиесе - «ТатРИТЭКнефть» НГДУсын оештырган иде. Бүген предприятие яңа нефть ятмаларын үзләштерә, разведка - бораулау эшләре алып бара, төп эше - нефть чыгару темпларын көннән - көн арттыра тора. Дөрес, кыска гына вакытта предприятиенең безнең җирдә эшчәнлегенә нәтиҗәләр чыгарырга иртәрәк әле, шуңа карамастан, яшь коллективның яңача эш ысуллары, производствода алдынгы технология куллану тәҗрибәсе укучы игътибарын җәлеп итмәслек түгел.***

РИТЭК АҖ үзе дә чагыштырмача яшь, бары тик 5 ел гына эшләүче компания. Ләкин шул дәвердә компания 6 юнәлештә эшчәнлек итүгә нигез сала: бораулау һәм ятмаларны эшкәртү, нефть чыгару, газохимия, нефть промышленносте машиналары төзү, социаль - экологик һәм фәнни - тикшеренү эшчәнлеге. Компания барлык юнәлешләрдә эшчәнлеген елдан - ел арттыра бара. Нәтиҗәдә җитлеккән производство структурасы оештырырга өлгерә. Хәзер РИТЭКның төрле предприятиеләрен дәүләт картасының төрле почмакларында күрергә була: Себер, Ханты - Мансийск, Кырым, Мәскәү, Татарстан... Соңгысына килгәндә, 1995 елда компания конкурс нигезендә ятмаларны үзләштерүгә лицензия хокукы ала. Шуларның Енорусскин (Аксубай районы) ятмалары озак сроклы (25 ел) аренда нигезендә эшкәртелүгә тапшырыла. Начальник итеп элек «Лениногорскнефть»тә эшләгән А.С.Якимов билгеләнә. 1996 елның августында РИТЭК АҖ нефтьүткәргечтән беренче продукциясен җибәрә башлый. Озакламый нефть ятмалары булган Кыязлыда да эш җәелдерелә. Бүген предприятие шул ике ятмада 22 скважинаны 18 км.ны тәшкил иткән гамәлдәге нефть үткәргечкә тоташтыра, Шулардан тәүлегенә уртача 250 меңәр тонна нефть чыгарыла.

Яңа ятмалар «Татнефть» АҖ тарафыннан табышсыз - азпродуктлы һәм геологик - физик параметрлар да катлаулы дип табылганга, аларны үзләштерүдә стандарт булмаган чараларны куллану таләп ителә. Беренче планга - оештыру, техник һәм иң мөһиме экономик бурычлар чыга. Ятмаларны үзләштерүдә иң арзан юлларны сайлауга, бөтенъяклап экономиягә, башлыча иң нәтиҗәле саналган техника һәм технологияне куллануга зур игътибар бирелә. Бу очракта бораулау һәм нефть ятмалары булган җирләрне төзекләндерү этапларын югары темпларда башкару максималь экономик нәтиҗәгә ирешү өчен иң мөһим шарт булып тора.

Яңа технологияләргә килгәндә, катламга югары температура нигезендә депрессияләү куллану әйбәт нәтиҗәләр бирә. Бер скважинаның бер үк вакытта дүрт продуктлы катламда эшләве дә предприятиегә зур экономик эффект китерә. Күптән түгел шундый технология белән нефть суырту өчен Россиядә әле беренче Америка җайланмасы сатып алына. «ТатРИТЭКнефть» НГДУсы җитәкчесе әйтүенчә, аны эшкә җибәрү, ә ул озакламый урнаштырылачак, предприятиенең дебетын (керемен) ике тапкырга диярлек арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Шулай предприятие биш елдан чыгымнарны тулысынча аклап, Норлатта рентабельле производствога әверелергә ниятли, моның өчен нефть ятмалары җитәрлек.

Енорусскин, Кыязлы Аксубай районы җирендәге ятмалар булса да, анда эшләүче 50ләп кеше норлатлылар. Шәһәрдә эшсезлек арткан бер чорда яңа эш урыннары барлыкка килү Норлат өчен беренче плюс. Хәер, бу мәсьәлә аерым тукталуны сорый: безнең район чагыштырмача яшь нефть җире булганга һәм алар нигездә «Норлатнефть» НГДУсында тупланганга, РИТЭКта кадрлар проблемасы кискен тора. Шул сәбәпле әлегә экономик, технологик хезмәт, капиталь төзелеш службалары булдырылмаган. «Рәхмәт, М.М.Хуҗинга, ул үзенең берничә белгечен биреп, безгә зур ярдәм күрсәтте»- ди А.Якимов.«Барысын да кадрлар хәл итә» дигән мәгълүм принципка таянып, предприятие әзерлекле, квалификацияле һәм иң мөһиме спецификасы ягыннан тиң эш сораучыларны гына кабул итә. Гомумән, профессиональлеккә өстенлекне бирү, алга киткән илләр тәҗрибәсенә нигезләнеп тар белгечлеккә таяну (бу очракта бары тик нефть чыгару гына) РИТЭКның эшчәнлегендә хәлиткеч принциплар, диярга мөмкин. Әмма бу үзләштерелә торган нефть ятмаларын төзекләндерү, юллар төзүгә комачауламый (бусы РИТЭКның биредә булуына икенче плюс). Боларны башкаруга алар үзләре төп эштән тайпылмыйча, килешү нигезендә махсус оешмаларны тарталар.

Ә инде район өчен өченче плюс: былтыр предприятиедән җирле бюджетка 309 млн. сум акча керсә, быел (әле ярты ел гына) ул 260 млн. сумны тәшкил итә. «ТатРИТЭКнефть» НГДУсы Татарстан президентының ягулык - энергетика чыгаруны тотрыкландыру программасына кергән, ә анда шуңа охшаш предприятиеләргә ярдәм күрсәтү мәсьәләләре дә карала.Соңгы чиктә булышлык үзен акларга тиеш. А.С.Якимов фикеренчә, нәкъ шундый компанияләргә нигезләнеп, Татарстанда нефть чыгаруны арттыру мөмкинлеге бар.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

### ҖӘЙ-МУЛ СӨТ ЧОРЫ

# БОЛЫН ИРКЕН, АЗЫК КҮП

Биляр Озеро якларыннан да матур җирләр бар микән? Безнең «Үрнәк» КХАсы эшчәннәренә дә эш мәйданы киң, маллар да үпкәләрлек түгел. Биредәге болыннар, күлләр артындагы иркен болында хуҗалыкның 350 баш терлеге көтелә. Сөт муллыгы маллар авызына нинди үләннәр эләгүгә дә бәйле. Бу җәһәттән көтүче быргысы һәм көтүче кураена тукталасым килә. Алар бит гомер-гомергә көтүче күңелен ачу өчен түгел, ә аңа маллар белән идарә итү өчен хезмәт иткәннәр. Сыер - сизгер хайван, ул курайның тыныч тавышына тиз күнә, иркенләп ашап йөрүен белә. Ә тыныч көтү - ул шул ук сөт арту дигән сүз. Гомумән, маллар гадәтләре турында озаклап сөйләргә мөмкин булыр иде. Товарлыклы - сөтчелек фермасы савучысы Лидия Соренкова менә нәрсәләр сөйли: «Сыер - бик ягымлы, кешегә, ферма тәртибенә тиз ияләшә торган мал. Шуңа да аны караганда вак нәрсәләр булырга тиеш түгел. Сыерны дөрес саву, аның имчәкләрен карау малның сәламәтлеген генә түгел, мул продукция дә тәэмин итү дигән сүз ул. «Бу фермада нәкъ менә тиешле тәртип, эшне дөрес оештыру булганга продукция җитештерү хуҗалык буенча чагыштырмача дәрәҗәдә әйбәт тә. Сөтнең сыйфаты да яхшы- майлылыгы 3,9 процентка җитә, ди ферма лаборанткасы Галина Куприна. Сөйләшүгә ферма мөдире дә кушыла. Ул сөт муллыгында зоотехник Ә.Мамаюсупов һәм бригада ветврачы Г.Токаревның роле зур булуны билгели. Алар икесе дә зур стажлы, тәҗрибәле белгечләр. Терлекчеләр Николай Иванович Белов, Александр Иванович Хабаров, Анатолий Яковлевич Белов, Николай Ильич Кириллов та хуҗалык рәисе В.И.Гавриловның төнге көтү оештыру турындагы күрсәтмәсен җиренә җиткереп үтиләр. Сыерлар өстәмә туклandырусыз да калмыйлар: алларында яңа чабылган үлән, су, тоз, башка элементлар бер дә бетеп тормый.

Савучылар турында аерым сүз. Тугызысының һәммәсе дә, аеруча Валентина һәм Надежда Митюхина, Елена Александрова, Лидия Лукъянова, Валентина Белова, Александра Максимова мактауга лаеклар.

- Алда торган кышлату чорына зур өметләр багълыйбыз. Азыкны мулдан әзерләргә тырышабыз, хәзер фермаларда реконструкция бара, кадрларыбыз да ышанычлы, - ди Василий Иванович Гаврилов. Быел моңарчы булмаганча, пенсионерларга бушлай 1әр тонна печән һәм үз транспорты белән 8әр кубик метр утын бирелә. Мондый игътибар өчен авыл халкы хуҗалык җитәкчелегенә рәхмәт укый. Игелек изгелек булып кайтсын.

**В.КОМОЛОВ.**
**Биляр Озеро авылы.**

Дмитрий Николаевич эш дигәндә ару - талуны, алны - ялны белмәс егетләрнең берсе. Ул яраткан эше итеп механизатор һөнәрен сайлый. 1983 елда армия сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, туган авылында эшкә кала. Дмитрийны механизатор һөнәренең авырлыгы да, авыл тормышының мәшәкатьләре дә куркытмый. Хуҗалыкның кайсы тармагына кушсалар да шунда җир җимертеп эшли ул. Дмитрий Николаевич куәтле К - 700 тракторы белән язын - көзен җир сөрә, кышын төрле эшләрдә була, ә җәен ул хуҗалыкта сенаж таптата.



**Рәсемдә: «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгы механизаторы Д.Н.Магарин.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# Цехлар ярыша

«Норлатнефть» НГДУсы администрациясе һәм профсоюз комитеты бу көннәрдә производствода югары культуралылык буенча НГДУның иң яхшы цехы исеменә конкурс йомгакларын ясады. Конкурска әзерлек чорында промышленность объектларын тәртипкә китерү, төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча күп эш башкарылды. Цехларда санитар көнкүреш шартларны яхшырту буенча да эшләр дәвам итә.

Конкурста цехлар ике группага бүлеп үткәрелде. Беренче группа цехлар буенча беренче урында 2 нче нефть һәм газ чыгару цехы коллективы (начальнигы Җ.Г.Мөхәммәтшин), икенче урында нефть чыгаруга комплекслы әзерлек цехы - ЦК ППН (начальнигы И.М.Фәхретдинов) дип табылды. Ә икенче группага кергән цехлар арасында беренче урынны УПРП - парафинны эретеп алу җайланмасы цехы (начальнигы Г.И.Шәйхетдинов), ә икенчене ЦПВС - пар һәм су белән тәэмин итү цехы (начальнигы А.М.Сергеев) коллективлары яулады.

Бүгенге көндә НГДУ эшчеләре арасында профессиональ осталыкка конкурсның икенче этабы төгәлләнеп килә.

**В.ПЕТРОВА,**
**хезмәт хакы һәм хезмәт бүлеге начальнигы.**

## Таныш булыгыз: Резидә Шәрәфиева

# «Сез миңа илһам бирәсез»

***Татар җыр сәнгатендә ул кинәт пәйда булды һәм шунда ук йөзләгән, меңләгән тамашачысын табарга да өлгерде. Үзенчәлекле моңлы тавышы өстенә, һәр җырны тамашачыга үзенчәлекле итеп, бөтен бер тәмамланган әсәр итеп бирә белүе дә әсир иткәндер тыңлаучы күңелен. Аның турында якыннанрак белергә теләүчеләргә шушы кечкенә әңгәмәбезне тәкъдим итәбез. Тумышы белән Минзәләдән булган, хәзер Яр Чаллыда яшәүче җырчы белән без татар яшьләр җыены көнне сөйләшеп алдык.***



***- Резидә, безгә калса, сез җыр сәнгатенә кинәт, өерелеп килеп кердегез... Моңа кадәр кая идегез?***

- Сезгә генә шулай кинәт тоелгандыр ул. Чынлыкта исә мин өч ел инде Яр Чаллыда, Ринат Гобәйдуллин җитәкчелегендәге җыр студиясендә җырлыйм. Аңа кадәр гомер буе килгән җырга тартылуымны төп белгечлегем - рәссам - бизәүче эше белән бергә алып барырга тырыштым. Әмма беренчесе көчлерәк булды - җыр җиңде һәм моңа мин бер дә үкенмим.

***- Тамашачы сезнең беренче «Бураннарга каршы барам» дип исемләнгән җыр альбомыгызны яратып кабул итте. Җырларның күбесе - яңалар, тамашачыга нәкъ сез беренче җиткергән әсәрләр. Бу - принцип эшеме, әллә?..***

- Җырларның күбесе - «Мин синең ярты җаның», «Мәк чәчәкләре», «Күз карашың китми күңелдән»», «Үкенерсең, сандугач» - ансамбль җитәкчесе Ринат Гобәйдуллин әсәрләре, шуңа аларны башлап мин җырлавым гаҗәп түгел. Яшермим: үзебезнең, җирле авторлар әсәрләрен, бигрәк тә беренче булып башкарырга яратам. Бу киң иҗат мөмкинлеге дә бирә, җаваплылык та йөкли. Җыр язмышы һәрчак аның беренче башкаручысыннан бәйле бит. Шуңа Н.Гыйматдинова сүзләренә Ганс Сәйфуллин язган «Норлатым» җырын башкаруны миңа тапшыргач та бик дулкынланып кабул иттем. Мин аны бик теләп, яратып башкардым, җырның популяр булып таралуын, яратып җырлануын бик телим.

***- Сезне Равил Шәрәфи кызы микән, диләр...***

- Юк шул!...

***- Гаиләгез белән таныштырсагыз икән...***

- Ирем Федор Андреев - керәшен татары, шулай ук рәссам - бизәүче.

***- Менә кайдан килә булыр сезнең сәхнә киемнәрендәге зәвыклык!***

- Мөгаен. Аларны без чыннан да ирем белән бергә тегәбез, бергә әзерлибез.

***- Ә җырларны?***

- Сәнгать җитәкчемнең ярдәме зур. Ә нигездә күбрәк күңел тартымы буенча «бизим» мин аларны. Һәр җырның башкарылу рәвеше, интонация, моңы әүвәл күңелдә туа бит. Мин шуны тыңлаучы илтеп ирештерерлек башкарырга тырышам.

***- Иҗат ниятләрегез нинди?***

- Хәзер икенче альбомымны әзерлим. Җырлыйсы, яңадан яңа җырлар башкарасы килә.

***- Норлат тамашачысына әйтер сүзегез бармы?***

- Мин сезнең белән очрашудан бик канәгатьмен, кадерле тамашачылар. Киләчәктә дә сезнең мәхәббәтне, игътибарны тоеп яшәсәм, иҗатыма зур илһам, терәк булыр иде ул.

***- Насыйп итсен! Уңышлар сезгә!***

**Әңгәмәдәш: С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

***02 хәбәр итә ● 02 хәбәр итә***

## Кайда һәлакәт, кайда бурлык

Кайвакыт тәүлеклек криминаль вакыйгалар бер айлыкка тиң була: 18 еннән 21 енә кадәрге көннәр һәм төннәр нәкъ шундый булгандыр, мөгаен. Көтелмәгән өч үлем теркәлде, шуларның икесе фаҗигале төстә.

* * *

Юл - транспорт һәлакәтендә 13 яшьлек Т. Әхмәтшин һәлак булды, 6 кеше тән җәрәхәтләре алды. Мәсәлән, Киекле авылы белән Богдашкино арасындагы юлда С. «Волга» машинасында бик җиңел генә, һичнинди хәвефсез элдертә. Мавыгып китеп алдагы машинаны узыйм дип, шофер тизлекне тагын да арттыра. Ахыры шул: «Волга» әйләнеп каплана, пассажир һәм шофер үзе шифаханәгә озатыла.

* * *

Исереккә диңгез тубыктан, күлләвек билдән, диләр. Бөгелмә автобазасының «Урал» машинасы шоферының көне нәкъ шундый була, ул атлар көтүен асфальт юл белән бутый. Ләкин мондый ялгышлык «Алга» КХА сына (һәм үзенә дә, әлбәттә) бик кыйммәткә төшә: 10 хайван шунда ук башларын салалар.

* * *

4 нче мәктәп ниндидер «музыкаль рухлы» кешеләр күзәтүе астында булган. Шулар җомганың караңгы төнендә мәктәпкә үтеп кереп музыка үзәген, магнитофонны урлап чыгалар. Әй, туйганчы уйнаталардыр. Һәрхәлдә, милиция эзгә төшкәнче...

* * *

Ә Лобачевский урамында берәү язын чебешләр алып, аларны үстерүгә күпме хезмәт куя һәм чыгымнар түгә. Аларга булган ышанычы, өметләре барысын да каплый дияр идең, юк. Һәммәсе җилгә оча, хуҗалар 20 баш тавыктан колак кагалар. Караклар йорт кошлары белән бергә 2 төргәк сетканы да калдырмыйлар. Анысы оя ясаргадыр инде.

## Шәфкать ияләренә рәхмәт.

**Миңа күземнең күрүе начарлану сәбәпле район үзәк шифаханәсендә дәваланырга туры килде. Бүлек мөдире М.Г. Галиев күземә операция ясап, мине дөньяне күрүемнән мәхрүм калудан коткарып калды. Бу гакыллы, олугъ белем иясе, шәфкатьле кешегә һәм күз врачы Р.З.Шабаевага олы рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Хөрмәтле һәм дәрәҗәле хезмәтегездә моннан соң да уңышлар юлдаш булсын, үзегез дә сау- сәламәт яшәгез.**

*Р.Гәләветдинов.*
*Бикүле авылы.*

***4676 нчы саклык банкының Октябрь бүлекчәсе***

***«Ашыгыч пенсия кертеме» тәкъдим итә.***

**Кертемнең төп шартлары:**

*** счет вкладчының пенсия таныклыгы нигезендә ачыла.**

*** кертемнең минималь суммасы 50 мең сум.**

*** процент ставкасы килешү срогына каралган арада үзгәрми.**

*** кертем буенча килешү 3 ай да 1 көнгә төзелә.**

*** яңа срокка автоматик рәвештә пролонгацияләү (процент ставкасы - пролонгация көнендәге).**

*** вкладчыга 50 мең сумнан да ким булмаган өстәмә взнослар кертү һәм тиешле процентларны алу мөмкинлеге бирелә.**

*Яңа кертем шартлары турында җентекле мәгълүматларны районның теләсә кайсы филиалыннан алырга мөмкин.*

## Котлыйбыз!

***Хөрмәтле Зәкия Исмәгыйловна!***

Сезне чын күңелебездән туган көнегез белән котлыйбыз. Сезгә озын гомер, сөенеп туймаслык шатлыклар, нык сәламәтлек, җан тынычлыгы, балаларыгызның игелеген күреп тыныч тормышта яшәвегезне телибез.

Алыгыз сез бездән олы тәбрик сүзен
Шушы булсын иң зур бүләкләр
Тыныч тормыш белән гел шат яшәгез
Озын гомер безнең теләкләр.

**«Березка» ашханәсе коллективы.**

## Белдерүләр

***Сатабыз***

**7 х 10 метрлы бура.** Адрес: Лермонтов ур., 3.

***

**Бортлы «ЗИЛ - 130», «Нива», «ГАЗ - 2412».** Ленино-горскида телефон: 2 - 21 - 68.

***

**Ленин урамында 14 - 2 адресы буенча 3 бүлмәле коттедж.**

***

**1994 елгы ЗИЛ - 131. Андреевка авылында Семенов П.И.гә мөрәҗәгать итәргә.** Тел.: 3 - 92 - 49.

***

**Ашыгыч рәвештә Кормыш микрорайонында хосусыйлаштырылган фатир.** Тел.: 5 - 22 - 09, (20 сәг.тән соң).

***

**Куллануда булган, әйбәт хәлдәге стенка, яңа кер юу машинасы «CANDY».** Тел.: 5 - 16 - 06.

***

**1992 елгы ВАЗ - 2121.** Тел.: 2 - 15 - 26.

***

**Күп функцияле балалар коляскасы (Германия).** Космонавтлар ур., 28 адресына мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2 - 20 - 13.

***

**ВАЗ - 2103, кыйммәт түгел.**
Адрес: Циолковский ур., 7 - 82.

***

**1984 елгы ВАЗ - 2107, бәясе - килешү буенча.** Адрес: Дружба ур., 78 - 51 (17 сәг.тән 22 сәг.кә кадәр).

***

**«Рено - 18» автомобиле.** Тел.: 2 - 12 - 69.

***

**Арбасы белән яхшы хәлдәге Т - 40М тракторы сатыла яки Норлатта 1 бүлмәле фатирга алыштырыла.** Киекле авылында Гайнетдингә мөрәҗәгать итәргә.

***

**Яхшы хәлдәге ГАЗ - 52.** Тел.: 5 - 18 - 21.( 16 сәг. соң).

***

**2,5 Х 3,5 метрлы гараж капкасы белән чана.** Мичурин ур., 19 адресына мөрәҗәгать итәргә.

***

**Иске Иглайда йорт, кыйммәт түгел.** Ленинградская ур., 14.

***

**Чабаксарда 3 бүлмәле фатир.** Главпочтампт, а/я 125 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

**4676 номерлы саклык банкының Октябрь бүлекчәсе 1997 елның 25 июленнән яңа кертем гамәлгә кертә:**

### *«Саклык кертеме».*

**Кертемнең саклану сроклары:**

**1. 1 айда бер көн - 1,5 процент.**

**2. 2 ай да 1 көн - 1,4 процент ай саен.**

**3. 3 ай да 1 көн - 1,3 процент ай саен.**

**Башлангыч взносның минималь суммасы - 300 мең сум.**

**Гарантияли:**

**1. Вкладны саклауның килешү нигезендә каралган срогында фиксацияләнгән процент ставкасын;**

**2. Процентларны ай саен исәпләү һәм аларны капитализацияләүне;**

**Мөмкинлек бар:**

*** Ай саен процентларны алу;**

*** Өстәмә взнослар кертү;**

**Өстәмә взнос размеры - 100 мең сумнан ким түгел.**

*** Вкладчы килмәгән очракта килешүне берничә тапкыр озайту (пролонгация). Договор әлеге суммага килешү озайтылган көнгә район филиаллары һәм учреждениеләрендәге процент ставкасы шартларында озайтыла.**

*Сезне районның барлык филиалларында көтәбез, сез бездә үзегезгә ошаган кертемнәрне ача аласыз.*

### *Ярминкәгә чакырабыз*

**29 июль көнне 8 сәгатьтә район мәдәният йортында Ульяновск күн комбинаты аяк киемнәрен сату буенча ярминкә үткәрелә. Киң ассортиментта ирләр, хатын - кызлар, балалар аяк киемнәре, галантерия товарлары бар.**

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә.